РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» июнь 2019 ел г. Альметьевск № 1190

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 ел 21 февралендә
кабул ителгән №248
"Әлмәт муниципаль районы
территориясендә реклама
конструкцияләрен урнаштыруга
һәм эксплуатацияләүгә килешүләр
төзү хокукына сәүдә үткәрү тәртибе
турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы №38-ФЗ Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 6 апрелендәге №180 карары нигезендә, ачыклау тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 21 февралендәге №248 «Әлмәт муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына сәүдә үткәрү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 кушымтаның 8 бүлектәге 8.2.4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Аукцион адымы лотның башлангыч (минималь) бәясеннән 20 процент тәшкил итә».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Район башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы Т.Д. Нагуманов

Зак. № 3063